ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.01.2022 с.Старое Дрожжаное № 42

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсендә эшләүче аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында, аларга бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 7 декабрендәге 1189 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 151 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 6 пунктта:**

а) 1 пунктчада "50" санын "8" санына алмаштырырга;

б) 3 пунктчада "айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкаларын" сүзләрен "бер айлык тариф ставкасы" сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктчада:

икенче абзацта “25” санын “5” санына алмаштырырга;

өченче абзацта "10" санын "2" санына алмаштырырга;

г) 5 пунктчада:

икенче абзацта “35” санын “7” санына алмаштырырга;

дүртенче абзацта "50" санын "10" санына алмаштырырга;

**2) 9 пунктта:**

а) беренче абзацта "(компенсация түләүләрен исәпкә алып)" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктчада «тугыз айлык тариф ставкалары» сүзләрен «бер бөтен сигез айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктчада "өч айлык тариф ставкалары" сүзләрен "бер айлык тариф ставкасы" сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 пунктта "айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкаларын" сүзләрен "бер айлык тариф ставкасы" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов